КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 май № 292

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждение-ләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел,

10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 нче кушымтаның 13 нче пунктында «(хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар өчен), – Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» ДАССУ» сүзләрен «, шул исәптән (хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар өчен) Чаллы шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» ДАССУЗ» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\292.doc